**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“24” ноябрь 2022 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Мөндеш торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш авылы территориясендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Мөндеш авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- авыл территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрне чабу,чистарту), хезмәтләр өчен түләү;
- Саттаров урамыннан чишмәгә төшү юлына чокыр аша басма ясау һәм урнаштыру (төзелеш материаллары сатып алу, эш һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү)

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Мөндеш авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Күңгәр авыл җирлеге Советы
5 округ депутаты: Абдуллин Р.Х.